**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Кукмара муниципаль районы**
**Оштырма-Юмья авыл җирлеге Советы**

КАРАР

2020 елның 28 нче гыйнвары 3 номерлы

Оштырма-Юмья авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2013 елның 25 ноябрендәге 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Оштырма-Юмья авыл җирлеге карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 25 ноябрендәге Оштырма-Юмья авыл җирлеге Советының 20 номерлы карарына (Оштырма-Юмья авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 39 номерлы, 2015 елның 30 маендагы 23 номерлы, 2015 елның 18 ноябрендәге 11 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 17 номерлы, 2018 елның 14 ноябрендәге 29 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 33 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 35 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 33 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кадастр хакының 0,1% ы – 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: www.pravo.tatarstan.ru, шулай ук Оштырма-Юмья авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында да.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

**Оштырма-Юмья авыл**

**җирлеге башлыгы урынбасары:** **М.М. Егорова**